ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

с. Шеланга

20.09.2018 год № 136

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, «Җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктына ярашлы Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Шеланга авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Шеланга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрүнең уртак инициативасын тәкъдим итергә:

"Сез 2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлегендә яшәүчедән 350 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

Берек авылының Үзәк урамында юл төзү;

Кызыл Байрак бистәсе зиратын төзекләндерү;

Нариман авылының Эшче урамында юл төзү;

Шеланга авылы зиратын һәм чишмәсен төзекләндерү;

Яңа-Юл бистәсе территориясендә балалар мәйданчыгы төзү.

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Шеланга авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л. Х. Закирова